**СОВЕТ**
**НОВОКИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
улица Советская, д.10, с.Новый Кинер,
Арский муниципальный район, 422031

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯҢА КЕНӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 10 нче йорт, Яңа Кенәр авылы,
Арча муниципаль районы, 422031

Тел.,факс (84366)9-12-65, (84366)9-12-68, 9-12-60. E-mail: Nkin.Ars@tatar.ru

**«26» октябрь 2015 ел** **№ 9**

## Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы
## КАРАРЫ

### Яңа Кенәр авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Яңа Кенәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы нигезендә Яңа Кенәр авыл җирлеге Советы карар бирде**:**

Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авыл җирлеге Советының 2014 елның 27 октябрендәге 102 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авыл җирлеге Уставына ( 2015 елның 18 июнендәге 138 номерлы үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

а) 5 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
“Әлеге статьяның 1 пунктындагы 14-15 пунктчасы 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.”

б) 6 статьяның 1 п. пунктында түбәндәге эчтәлекле 13 пункт өстәргә:
«13. Җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз йорт хайваннарын аулау һәм асрау чараларын гамәлгә ашыру.»

в) 33 статьяда:
- 1 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
« 1. Җирлек советы компетенциясендә:»;
- 1 пунктның 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«7) җирлекләрнең, шәһәр округларының коммуналь инфраструктурасы системаларын комплексцы үстерү программаларын, җирлекләрнең, шәһәр округларының транспорт инфраструктурасын комплексцы үстерү программаларын, таләпләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган җирлекләрнең, шәһәр округларының социаль инфраструктурасын комплексцы үстерү программаларын эшләү һәм раслау;»

г) 69 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:
«5. Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарларын кабул иткәндә муниципаль берәмлек башлыгы тавышы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты тавышы буларак исәпкә алына.»

д) 79 статьяга түбәндәге эчтәлекле 21 пункт өстәргә:
«21. Җирле бюджет проекты, җирле бюджетны раслау турындагы карар, аның үтәлеше турындагы еллык хисап, җирле бюджетны үтәү барышы һәм җирле үзидарә органнарының, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең саны турында квартал саен белешмәләр, аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнар рәсми басылып чыгарга тиеш.»

2. Әлеге карарны, ул кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә, Уставларны теркәү һәм дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органының территориаль органына җибәрергә.

3. Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгына уставларны теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органыннан Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән “Яңа Кенәр авыл җирлеге уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” карарны бастырып чыгарырга.

4. Арча муниципаль районының Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгына уставларны теркәү өлкәсендәге вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органына үзгәрешләр һәм өстәмәләр рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән алып 10 көн эчендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр чыганагы турында белешмәләр җибәрергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яңа Кенәр авыл җирлеге башлыгы Фәхретдинов Р.Ә.